**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23нчейортЛаешш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2021елның 9 феврале** **249 номер**

# КАРАР

**«Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортны) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 04 мартындагы 350 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының «Лаеш муниципаль районы башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 13 ноябрендәге 2027 карары нигезендә карар бирәм:

**1.** «Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортны) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 04 мартындагы 350 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә**:
«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча, башкару срогы Россия Федерациясе законнары нигезендә булган, бурычларның булмавы турында белешмә, (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш);
**Пункт 2.8 дополнить подпунктом 5** следующего содержания:
5) наличие задолженности по налогам, сборам и иным платежам в бюджеты бюджетной системы Российской Федерации.;
**3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:**
Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч барлыгы (булмау) турында белешмәләр.;

1. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәренд Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**